Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы
Олы Солтан авыл җирлеге составына керүче Олы Солтан авылы
торак пунктында үткән гражданнар җыены

**КАРАРЫ**

2020 елның 2 ноябре № 2

2003 елның 6 октябрендәге "Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 маддәләре, Татарстан Республикасының 2004 елның 28 июлендәге "Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында" 45-ЗРТ номерлы Законының 35 маддәсе, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Солтан авыл җирлеге составына керүче Олы Солтан авылы торак пунктында үткән гражданнар җыены нигезендә **карар кабул ителде:**

1. 2021 елда Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Солтан авыл җирлегендә тору урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән (уку йортларына көндезге бүлекләргә йөреп укучы студентлардан һәм 1 группа инвалидлардан гайре) 400 сум күләмендә үзара салым акчасы кертергә;
2. Салым акчасын түбәндәге эшләрне башкару өчен тотарга:
   - Олы Солтан авылында Комсомол, Р.Шәрәфеев, Бакча урамнарындагы вак таш җәелгән юлларны төзекләндерүгә (вакланган таш сатып алу, ташу, җәю, килешү буенча эш барышы өчен түләү);
   - кышкы чорда авыл җирлегенә керүче торак пунктлардагы юлларны карап торуга
3. Карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Солтан авыл җирлегенең түбәндәге адрес буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендында урнаштырырга: Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе районы, Олы Солтан авылы, Р.Шәрәфеев урамы, 12 йорт һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге "Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы"нда урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче: Р.Р.Сөнгатуллин

Олы Солтан авыл җирлеге башлыгы : Р.Р.Сөнгатуллин